ГЛАВА РОЖДЕСТВЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422631д.Дятлово,
ул. Юности, д.1
тел (факс): 8 84378 4-74-98

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 8 84378 4-74-98

---

2024 елның «12» сентябре 5 номер

# БОЕРЫК

Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән
файдалану төрен үзгәртү турында гавами
тыңлаулар билгеләү хакында.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге советының 2018 елның 10 декабрендәге 135 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, тормыш эшчәнлегенең уңайлы шартларына кеше хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында,КАРАР БИРӘМ:

1. Кадастр номеры 16:24:190502:3857 -код 4.4-кибетләр булган җир кишәрлегенә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1 Үткәрү датасы һәм вакыты – 2024 елның 21 октябрендә 15.00 сәгатьтә.

2.2 Үткәрү урыны-422631, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Дятлово авылы, Яшьлек ур., 1 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы.

2.3 Рөхсәт ителгән файдалану төренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Дятлово авылы, Яшьлек ур., 1 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге башкарма комитетына тапшырырга.

2.4 Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты 2024 елның 18 окябренә кадәр.

3. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Рождествено
авыл җирлеге Советы рәисе С.М. Гуцу